Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

28 март 2019 ел № 13

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районында һәм Әлмәт шәһәрендә халык алдында тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Алсу» микрорайоны территориясендә җир кишәрлекләренә карата планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү проект документациясе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:

- кадастр номеры 16:45:050112:389, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районые, Әлмәт шәһәре, Ринат Галиев урамы, 35 йорт адресы(территорияне планлаштыру проекты буенча К/4.11-1 позициясе) буенча урнашкан:

- кадастр номеры 16:45:050112:380, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 8 адресы (территорияне планлаштыру проекты буенча К/1.2.3-1 позициясе);

- кадастр номерлары 16:45:050112:409, 16:45:050112:410, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 76 адресы (территорияне планлаштыру проекты буенча К/1.2.3-1 позициясе);

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 12 апрелендә 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә ике һәм өч айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4.Планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү проект документациясе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 12 апарелендә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык

алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы А.Р. Хайруллин